Ислам даирәһе



# Бөйөк Болғарға сәйәхәт

**Дилә БУЛГАКОВА**

Ҡояш услап-услап ергә нурҙарын һибә, ни өсөндөр быйыл тәбиғәт ямғырҙарға һаран булды шул. Ләкин барыбер күптәрҙең һағынып көтөп алған "Бөйөк Болғарға сәйәхәт-2010" йөҙҙән ашыу кеше йыйҙы.

С.Зайцев исемендәге пароходта ҙур талант эйәһе - Фәриҙә апай Ҡудашеваның йырҙары яңғырай. Был сәйәхәт моңлы йырсыбыҙҙың 90 йәшенә арналған да инде.

"Беҙ бәхетле: беҙ йәшәйбеҙ Өфөлә һәм Ҡазанда, Ҡабатланмаҫ нәфис йырсы Фәриҙәле заманда", - тип яҙған ине Хәсән Туфан.

Болғарға сәйәхәтте бына инде 19-сы тапҡыр теплоходта ойыштырыусы - Башҡорт дәүләт опера һәм балет театрының солисы, "Рамаҙан" йәмғиәтенең президенты, оло йөрәкле йырсы Марат Шәриф әфәнде. Был сараның программаһы ла бик бай булды: "Рамаҙан" радиоһының тапшырыуҙары яңғыраны, ҡатын-ҡыҙҙар өсөн дини дәрестәр үткәрелде. "Рамаҙан" мәҙрәсәһен ойыштырыусы һәм мөғәллимә - талантлы Венера Ғималова булды. Юл буйына төрлө милли уйындар, һабантуйҙар, Ҡазан менән танышыу, Ҡол Шәриф мәсетендә булып - вәғәз тыңлау, дин әһелдәре менән осрашыу мөмкинлеге булды.

Айнур, Ратмир, Флүрә Туйсиндарҙың, Рәсим Низамовтың, Халит һәм Лилиә Фатыховтарҙың концерттары, Фәриҙә Ҡудашеваның юбилей кисәһе, Роза Сахаутдинова, Гөлфиә Юнысованың ижад кисәләре булып үтте.

# ШӘҖӘРӘМНЕҢ КЫЛЫ...

*Гасырларны актарганнар,*
*Дөреслеге кайсыдыр ул?*
*Безгә баккан Айдагы кыз*
*Болгар кызы Асылдыр ул.*

*Яшәгәннәр, яшьнәгәннәр,*
*Шаулап-гөрләп гомер иткән.*
*Бөек Болгар дәүләтенә*
*Сансыз гасыр үтеп киткән...*

*...Изге җиргә баш иелгән,*
*Без сәфәрче менә бүген.*
*Каберләрнең ак ташлары*
*Саклап калган хәтер җебен...*

*Чиркәүләрнең нигезендә*
*Кабер ташы - шаһит булыйк.*
*Барысының рухына*
*Хәер биреп, дога кылыйк.*

*Дин әһелләр бер Аллаһка*
*Ярдәм сорап табынгандыр.*
*Тәне - җирдә, ә җаннары*
*Йолдыз булып кабынгандыр.*

*Болгар кызы бу юлларга*
*Айдан баккан - карый күктән.*
*Язасы кыз язмышын да,*
*Беләм кебек аны күптән.*

*...Урман итәгендә авыл,*
*Урман серле, безгә бик ят.*
*Яшәгән, ди, сунарчы кыз -*
*Асыл, чая Өммехәят.*

*Зифа буйлы, зәңгәр күзле,*
*Дулкынланып торган толым.*
*Урманының белгән серен,*
*Сукмакларын, һәрбер юлын.*

*Сөйгән кызый табигатьне,*
*Җан иясен - кошчыкларын,*
*Чәчәкләрнең таҗларына*
*Таңда кунган таң чыкларын.*

*Табигатьнең бар мизгеле*
*Аның өчен якын булган*
*Тирә-ягын матурларга*
*Болгар кызы шунда туган...*

*Чулман елга сәүдә иткән,*
*Йөзгән икән зур кораблар.*
*Идел йорты - Нур Болгарга*
*Килгән мөселман гарәпләр.*

*Сәхабәләр, сәфәрчеләр*
*Ерак илдән килгән - чүлдән...*
*Сулар аша, еллар аша,*
*Мосафирлар күпләп килгән...*

*Бер мосафир бик соң гына*
*Сылукайга кага ишек.*
*Сәлам биреп керүчегә*
*Биксез капка, ачык ишек.*

*Сунарчы кыз сүзсез генә*
*Сыйлаган ул гарәп углын.*
*Ят мосафир төшендергән*
*Дин тарату изге юлын.*

*Аш-суына ят юлаучы*
*Дога кылган аларга хас.*
*Госелләнгәч, азан әйтеп,*
*Укыгандыр ахшам намаз.*

*Нур таралган тирә-якка,*
*Ишетелгән моңлы азан.*
*Йокламыйча дога кылган*
*Юл-сәфәрче - ят мөселман.*

*Күпләр моңа каршы төшкән, -*
*Ислам дине нигә кирәк?*
*Исмәгыйльне мыскыл итеп*
*Чыгарганнар өйдән сөйрәп.*

*Гарәп углы бер Аллаһка*
*Намаз укып, ярдәм сорап,*
*Изге дингә өндәп үзе*
*Йөрегән, ди, авыл буйлап.*

*Өммехәят дин кешесен*
*Үз өендә тугры көткән.*
*Япь-яшь кызый иң беренче*
*Ислам динен кабул иткән...*

*Никах белән кавышканнар,*
*Искән җилләр торган тынып.*
*Олы дөнья, кыр-урманнар*
*Башын игән шаһит булып.*

*Өммехәят вә Исмәгыйль*
*Мәчет салган пакь имәннән.*
*Тәрәз уеп, аен элгәч,*
*Ак мәчеткә кергән, ди, җан.*

*Нәни урам итәгендә*
*Айлы мәчет нур тараткан.*
*Тирә-якның авылларын*
*Чакырып торган бик ерактан.*

*Өммехәят, дин өйрәнгәч,*
*Хатын-кызга белем биргән.*
*Намаз уку тәртипләрен*
*Өйрәнергә күпләр килгән.*

*Табигатьнең мизгелләре,*
*Җилләр сипкән еллар көлен.*
*Бөек Болгар кабул иткән*
*Иң беренче Ислам динен.*

*Ул дәвердә аксакаллар*
*Хаҗга барып урап кайткан.*
*Дин таралган, әүлияләр,*
*Хаҗ ияләр күпләп арткан.*

*Мизгелләр килеп киткәннәр,*
*Вакытлар тукталмаган.*
*Гөрләп торган зур дәүләтне*
*Юк итәрлек ут табылган.*

*Асу-кысу тәкъдиреме -*
*Юкка чыккан Бөек Болгар.*
*Тигезләнгән бар тереклек,*
*Актарылгач җирдән комнар...*

*Кара пулат диварларың*
*Сөйләмәсме телгә килеп?*
*Тыныч йокла, Шәһри Болгар,*
*Тубыкланам дога кылып!*

*...Сагаеплар Чулман -*
*бәбәй итәк*
*Диңгезләргә ага кайдадыр.*
*Шәһри Болгар барына да*
*шаһит,*
*Соңгы болгар кызың Айдадыр...*

**Дилә БУЛГАКОВА.**

# Уразаға хөрмәт күрсәтү

**Әхмәд ШАҺИН**

Билгеле булганча, гыйбадәт кылган кеше аны бөтен кешегә күрсәтеп эшләми. Бу эш һәр инсанның шәхси эше. Дөрес, шулайдыр. Шулай да гыйбадәтне яшермичә башкару да гаеп эш түгел бит. Гыйбадәттән кешегә зыян-зәүрәт килми. Киресенчә, гыйбадәт кылган кешегә башкалары карап, аларда да гыйбадәт кылу теләге уяныр, вөҗданнары хәрәкәткә килер, коллык вазифаларын үти башларлар дигән өмет бар. Бу аеруча уразага кагыла.

Ураза тотмау исә гаеп эштәр. Һәм янындагы ураза тотучыга да, һәм җәмгыятькә дә, һәм Раббыбызга карата гаеп. Ураза тотмауның ике төре бар. Мәсәлән, мөселман кешесе, ураза тотмаса да, кеше күрмәгәндә генә ашап-эчә. Бу бары тик аның шәхси мәсьәләсе, Аллаһ каршында шәхси җаваплылыгы. Ләкин ил-көнгә күрсәтеп ашаучылар да бар. Болар гөнаһларын яшерми, оялмый-тартынмый. Менә монысы инде зур гөнаһ. Ягъни мондый кеше үз гөнаһы белән генә калмый, аны уразада ачыктан-ачык ашавын күргән кешеләр ахирәт көнендә шул гөнаһларга каршы шаһитлык кылачаклар. Ачыктан-ачык гөнаһ кылган мөселман бәндәне "фасыйкы мөтәҗаһир" диләр. Элекке заманнарда мөселман җәмгыятендә андый кешенең таныклыгы кабул ителмәгән, аңа кыз бирмәгәннәр, мөһим эшләрдә аның белән хезмәттәшлек итмәгәннәр. Хәлбуки мөселман уразасын хөрмәт күрсәткән мәҗүси дә Аллаһның рәхмәтенә лаек булган, ул хөрмәтнең мөкяфәтен - әҗерен күргән. Моны тарихи мисаллар дәлилли.

Шулай Рамазан керергә бер көн кала мәҗүси үз өенең ишегалдына икмәк ашап утырган баласына болай ди: "Улым, иртәгедән башлап икмәкне тышта түгел, өйдә ашарсың. Без мөселманнарга ихтирамлы булырга тиешбез. Алар бер ай буенча, Тәңреләренә итагать итеп, ураза тотачаклар!"

Бер көн килеп җитеп, бу мәҗүси вафат була. Җеназасында мөселманнар да була. Шуннан мәҗүсинең бер күршесе төшендә мәрхүмне күреп, аннан сорый икән:

- Йә, хәлләрең ничек, син исән чакта утка табына идең, анда ут белән мөнәсәбәтең ниндирәк соң?

Җавап бик гыйбрәтле була:

- Юк, минем хәзер ут белән һичнинди дә алыш-бирешем юк. Чөнки мин мөселман булараk вафат иттем. Үлеп барган чагымда Газраил килгәч, Раббым аңа: "Әй Газраил, бу колыма шәһадәт кәлимәсен өйрәт, ул аны әйтсен. Шул рәвешчә, хозурыма иман белән килсен. Мин аның иманлы булып үлүен телим. Чөнки ул мөселманнарның уразасына хөрмәт күрсәтте. Рамазан ае дәвамында балаларын өендә генә ашатты, ишегалдына чыгып ашарга рөхсәт итмәде. Уразага һәм ураза тотучыларга хөрмәт күрсәткән колыма мин иман насыйп иттем", - дип әйтте.

Сүзнең кыскасы: ураза тотмаучылар һич булмаса шул мәҗүси кадәр генә җәмгыятькә хөрмәт күрсәтергә тиештер, минемчә. Дөресме?

# Ураза тоту серләре

***- Тешләрне дәвалау, күзгә, борынга дару салу уразаны бозамы?***

- Пломба куйганда яки теш суыртканда әгәр тамактан эчкә кан яки башка берәр матдә үтмәсә, ураза бозылмый. Ләкин теш алдырган вакытта, гадәттә, табиб анальгетик дару кулланып укол кадый. Андый вакытта, ягъни организмга дару кергәндә, ураза, һичшиксез, бозыла. Бу рәвештә уразасы бозылган кеше аны соңыннан каза кыла.

Югарыда язылганны исәпкә алып, болай эшләргә киңәш ителә: теш суыртуны ифтардан соңгы вакытка билгеләргә кәрәк.

Күз, борын яки колакка дару салуга килгәндә, бу хакта төрле карашлар бар. Ләкин шуны әйтергә мөмкин: күз һәм колакка тамызылган дарудан ураза бозылмый, ә инде дару борынга салынса, ул үңәч һәм ашказаны белән бәйле булуы аркасында уразаны боза дип уйланыла. Шулай булгач, борынга дару тамызу зарурияте бар икән, аны авыз ачканнан соң башкарырга кирәк.

***- Күрем булачак көнне уразага ният ителмәсә ярыймы?***

- Ярый. Чөнки ул көнне күрем күрсә, ният итмәве дөрес була. Әгәр инде күрем башланмаган булса, уразаны каза кылыр. Иң яхшысы шул: күрем башланыр дип фараз иткән көнне ураза тоткан хатын-кыз күреме башланган вакытта ук уразасын бозарга тиеш. Ягъни ашап яки эчеп куярга. Билгеле, алдан даруны эчеп, күремне Рамазаннан соңгы вакытка кичектерергә теләүчеләр дә бардыр.

Тик мондый очракта сәламәтлекне дә онытырга ярамый. Чөнки төрле организмга дарулар төрлечә тәэсир итә. Иң мәслихәте: уразаны тотарга, күрем күрә башлагач та ашап-эчәргә, калдырган көннәрне каза кылырга. Чөнки "тот!" диюче дә - Раббыбыз, күрем башлангач, "аша!" диюче дә - Раббыбыз. Бер мәшһүр Ислам галиме болай дигән: "Әй ханымнар! Сез Аллаһның Бәхетле коллары. Уразаны тотып савап аласыз, ашагач, янә савап аласыз. Чөнки ике очракта да Раббыгызның әмеренә буйсынасыз".